ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**20.03.2025** **г.Чистополь** **№ 118**

Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль
районы»муниципаль берәмлеге Башкарма
комитетының «Суд тарафыннан хокукка сәләтсез
яисә хокукка сәләте чикләнгән дип яңа
редакциядә танылган гражданнарга карата
опека һәм попечительлек өлкәсендә
хезмәт күрсәтүләрнең административ
регламентларын раслау турында»
2018 елның 17 декабрендәге 1030 номерлы
карары үз көчен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыклары белән расланган гамәлдәге Административ регламентларга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 17 декабрендәге 1030 номерлы карары белән расланган хокукка сәләтсез дип яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган гражданнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларыннан файдалану кирәклеге бетүгә бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип яисә хокукка сәләте чикләнгән дип яңа редакциядә танылган гражданнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2018 елның 17 декабрендәге 1030 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлегенә (Сударкина С.А.) әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов